Эльмира Шәрифуллина
Җитәкләшеп
җил белән

Эльмира Шәрифуллина

Җитәкләшеп җил белән

Казан
Татарстан китап нәшрияты
1990

ББК 84 (2Р-Тат)-5
Ш 95

Художнигы И. ГАЛЛӘМОВ

Ш $\frac{4803010200-158}{М 132(03)-90}$ 189—90

ISBN 5—298—00489—X

© Эльмира Шәрифуллина, 1990

ГӨЛ ҮСТЕРӘ ГӨЛНАРА

Гөлнара күзен ачканчы
Якты уянган икән.
Якты иртә уянганга
Гөлләр куанган икән.

Гөл чәчәге елтыр-елтыр
Елмая Гөлнарага.
Чиләгенә җыйган яңгыр
Суын сибә ул аңа.

Гел елмаеп торсын гөлләр
Гөлнара торган төшкә.
Гөлләргә су сибә-сибә
Өйрәнә кызлар эшкә...

КОЯШЛЫ УЕН

Яуды яңгыр, яуды яңгыр,
Күлләвекләр җыелды.
Чулт-чулт итеп агачлардан
Шук тамчылар коелды.

Шатлыгыннан кош сайрады,
Кояш чыкты ялтырап.
Ап-ак томан җиргә ятты
Иртә таңнан, ял сорап.

Әнә салават күпере —
Ал, кызыл басмалары,
Гүя ул нәни кызларның
Чәчүргеч тасмалары.

Уянды бөтен табигать,
Гөлләр нурга коенды.
Яңгыр үзе башлап китте
Бу кояшлы уенны.

СЕРЛЕ ДУЛКЫННАР

Җилләр, җилләр,
Көй уйныйлар,
Ә дулкыннар бииләр.
Бииләр парлап,
күбәүләп,
Кара, нинди җиллеләр.

Кул чабалар яр буенда
Үзләренә үзләре.
Серле иткән — дулкын икән
Бу олы диңгезләрне.

ЕЛМАЕГЫЗ, КӨЛЕГЕЗ

Елтыр-елтыр елтырыйм,
Челтер-челтер челтерим,
Ерганак мин — кар суы,
Елгага агам туры,
Елларга агам туры...
    Җыр башладым, тыңлагыз,
    Юк, кушылып җырлагыз.
    Дәртле, нурлы яз иңсәмдә —
    Бии, бии җырлагыз,
    Моңаешып тормагыз.
Йөгерешеп йөрегез,
Һәм челтери белегез.
Хәтта кояшсыз көндә дә
Сез елтырый белегез —
Елмаегыз, көлегез!

ЯЗ КИЛӘ

Иртәрәк тора кояш,
Җилләр дә хәзер юаш.
Су — тәгәрмәч эзендә,
Булыр чыпчык тезеннән.

Ямьләнде бөтен җиһан,
Суыкка дөнья кысан.
Җылы һәм нуры кавышты,
Көннәр язга авышты.



БҮЛӘК ӘЗЕРЛӘГӘНДӘ

Йөзебез нигә яктымы?
Серләшәбезме нигә?
Бүләк турында сүзебез
Туган көнгә әнигә.

Күз явын алырлык булсын
Без әзерләгән бүләк.
Әйтмичә дә аңлашылсын
Яхшы уй, изге теләк.

Киңәшәбез. Энем белән
Без икебез бер уйда.
Шундый бүләк ясыйк, хәтта
Искә алсыннар туйда...

ӨМӘ КӨННЕ

Кардан ачылгач урамнар,
Яланнар, өй яннары
Себереп түгәләр иң элек
Кыш җыелган чүп-чарны.

Яшел чирәм иркен сулап,
Матур булып үссен дип,
Шул матурлык күңелләргә
Һәм эшләргә күчсен дип,

Җыр тусын, дип, пөхтәлеккә,
Чисталыкка сокланып.
Чүпне себереп түгү өчен
Өмәгә чыга халык!

НИЧЕК ТҮЗГӘН?

Озын кышлар үткәнче
Җир-ана ничек түзгән?
Изүен чишеп җибәргән,
Яшел күлмәген кигән.

Җылы сулышын өрә ул
Карлы тау итәгенә.
Яр битеннән, басулардан
Сөттәй пар күтәрелә.

ҖӘЙ АЕ

Чәкердәшәләр чәчәкләр:
— Җәй бит, җәй җитә,— диләр.
Әнә кара куакларга,
Күпереп кенә киттеләр.

Җылы яңгыр явып үтте
Җирне яшелгә буяп.
Син кагыл да, җилгенәем,
Урман-кошларны уят.

Уйнап күбәләк куарга
Җәй ае керсен иде.
Тизрәк су керергә күке
Рөхсәтен бирсен иде.

АК ЮЛ КИРӘК

Ак мамыктай кар көтә
Минем агач көрәгем.
Яңа елга чыгарга
Ап-ак юллар кирәген
Онытты кар болыты.

Җилем, җилем, җилкәем,
Көчле дә син, җитез дә,
Аңлачы хәлебезне,
Ак дөнья кирәк безгә,
Пакь дөнья кирәк безгә.

Алып кил кар болытын
Ап-ак кар яудырырга:
Шәһәр-шәһәр уйнарга,
Таудан чана шуарга,
Яңа елга чыгарга,
Ак юллар кирәк безгә,
Пакь еллар кирәк безгә!

ЯШЕЛ ЧЫРШЫ, ЯШЬ ЧЫРШЫ

Әй, чыршы, яшел чыршы,
Безнең өйгә кердең син,
Кергәч әллә шатландың,
Әллә үксеп көлдең син.

Бер генә көн сиптең дә
Тәмле ылыс исеңне,
Коелды ылысларың —
Үзгәрттең син төсеңне.

Әй, чыршы, нәни чыршы,
Сине кайчан аңларбыз?
Бер көнлек бәйрәм өчен
Сине кисеп алабыз.

Уенчык шарлар асып,
Түргә куеп бизибез.
Аннан урын — чүплектә,
Аннан сине белмибез,
Хәтта сәлам бирмибез,
Их, безне...

ҖӘЯҮЛЕ БУРАН

Аяклары күренмәгәч,
Ышанмый идем бер дә.
Юри буран көнне чыктым
Чаңгы киеп,
Йөрергә.

Тау итәгенә җитәрәк
Арыды күреп торам.
Әкренәйде,
Туктап калды,
Җәяүле икән буран...

АВЫЛГА ЦИРК КИЛГӘЧ

Зур яңалык бу елда —
Цирк килде авылга.
Әй, җыйналды малайлар,
Апайлар һәм агайлар.

Әбиләрне әйткән дә юк,
Әтиләр килгән хәтта.
Сакаллы сабый — бабайлар
Алда беренче рәттә.

Ат биетәләр уртада —
Ял төпләре ак күбек.
Әй, шатлана авыл халкы
Беренче күргән кебек.

Юбка кигән мәчеләргә,
Җигелгән эткә карап,
Ул кул чаба карты-яше,
Шатлана, бер дә харап:

Өйрәтә белгәннәр, имеш,
Сарык белән кәҗәне...
Цирк карый авыл халкы —
Арта дөньяның яме!..

АТА КАЗ

Күргәнегез бармы сезнең
Ата каз биегәнен,
Нәни бәбиләре чыккач,
Кычкырган, сөенгәнен.

Ул каңгылдап, әнкә казны
Яратып сөйләшкәнен,
Сары йомгак бәбкәләргә
«Таң-таң» дип эндәшкәнен.

Таң атты дип шатланса да,
Юаш икән бу, димә:
Ата каз булганда берүк
Бәбкә янына килмә.

ҮРТӘСЕН ӘЛЕ МИНЕ

Сөйләп киттеләр бары:
Кошлары, хайваннары...
Мәче әйтә: «Бик күптән,
Никтер, ул миңа дошман.
Гел кычкыра, гел шаулый,
Мине үртәп мыраулый».

«Дөрес, дөрес,— ди Акбай,—
Кәли бик усал малай.
Рәнҗетә ул мине дә,
Әле беркөн килде дә,
Җикте бит, әй, чанага —
Шуннан үзең чамала...

Инде тыңлыйк үрдәкне:
«Ул мине дә йөдәтте.
Юкка-барга бәйләнә,
Тилгән булып әйләнә.
Үземә таш ыргыта,
Бәбкәләрем куркыта.»

Бик озак сөйләштеләр,
Шактый күп киңәштеләр.
Тик күз кысып бер якта,
Тора сыңар аякта —
Ата каз ул: «Кыйгак,— ди,—

Торасызмы, елап? — ди,—
Китерегез Кәлине,
Үртәп карасын мине!..» —
Дип, елмая ата каз,
Ник елмая ата каз?

ТУЙГАЧТЫН БАЛ ДА ӘЧЕ

Көннәрдән шулай беркөн
Чирләгән соры мәче.
Айгөл сөйгән, сыйлаган:
— Аша инде, мә, мәче!

Сөйгән саен ныграк
Сөйдергән соры мәче.
Сөткә бал салып биргәч тә,
Мәче әйткән:
— Юк, әче...

Дарулар да биреп баккан,
Мәтрүшкә дә кайнаткан.
Ошап киткән иркәләнү —
Мәче урынга яткан.

Ап-ак урын-җир өстендә
Мыраулый соры мәче.
...Иркә мәче кебекләргә
Туйгачтын бал да әче.

РЕЗЕДА МАТУР КЫЗ

Резедәкәй зур үскән,
Апасы белән кичтән
Табак-савытлар юа,
Юа да сөртеп куя.

Чыланса да күлмәге,
Матур аның теләге —
Өйдә булсын чисталык.
Килә эшкә остарып.

КУРЧАКЛАРНЫҢ АПАСЫ

Курчакларын тәрбияли,
Бигрәк уңган кыз кеше,
Чисталыкларын тикшерә:
«Сызламыймы,— ди — теше?»

Тикшерә сулыш юлларын,
Колак, күзен, барчасын.
Ул бит бүген нәниләрнең
«Сула-сула» апасы.

Ә аннан соң дару яза,
Файдалы киңәш бирә:
«Елмаеп торма, курчагым,
«Сула апаң» ул белә.

Ятмыйм дисәң көннәр буе,
Чирләп урын өстендә,
Эч мин биргән даруларны
Калдырмыйча берсен дә».

РӘСЕМ ДӘФТӘРЕ

Бу рәсемнәрнең барсын
Ясаган идем үзем.
Бусы абый, бусы песи,
Монсы сеңлем — Гөлйөзем.

Менә тагын өчәү бергә,
Менә монда карагыз.
Барыбыз да үсеп җиткән —
Айга менеп барабыз.

КЕМ БУЛГАН ӘБИ-БАБАМ?

Кем булган минем әби?
Беләсең килсә әгәр,
Башта булган ул бәби,
Аннан булган ул әни,
Аннан булган ул әби.

Кем булган бабам Нәби?
Беләсең килсә әгәр,
Башта, башта, иң башта
Бабам да булган бәби.
Аннан булган ул Нәби,
Аннан булган ул әти,
Беләсең килсә әгәр...

ҖИҢЕЛ АЯКЛЫ АПА

Әбиемнең бер сүзе бар
Әлеге дә баягы:
«Юл уң була күрше апаң
Күрсә, җиңел аягы.»
Нигә җиңел?
Күргәнем юк
Яланаяк йөргәнен.
Җәй дә, кыш та,
яз да, көз дә
Кия кеше кигәнен.

Күп күзәтә торгач, тәмам
Сәбәбен белдем бугай.
Йөгереп кенә күрше апа
Фермадан кайта шулай.

Йөгереп кенә суга китә
Көянтә-чиләк асып.
Мин уйланып карап калам
Капка төбенә басып.

Йөри кебек аяклары
Үзләреннән-үзләре.
Күрәлми дә каладыр шул
Әбиемнең күзләре...

ТӘМЛЕТАМАК НӘРКИС

Ярата безнең Нәркис
«Барбарис», «Тузик», «Кис-кис».
Көне буе суыра,
Шул көе дә шудыра.

— Сәбәбе нәрсә, Нәркис,
Бик яратасың «Кис-кис?»
— Ашасам күбрәк «Кис-кис»,
Зур үсәрмен,— ди Нәркис.

Теләге үсү икән,
Үскәч ни кылыр микән?
Елмаеп әйтә Нәркис:
— Күбрәк ашармын «Кис-кис».

УЕННАН УЙМАК

Башым кашып тордым әле
Бик озак уйлап.
Ничек килеп чыга икән,
Уеннан уймак?

Алдым бер калай кисәге
Уйнаган булып.
Түгәрәкләп китердем дә
Беркеттем сугып.

Бизәген дә ясап куйдым
Шаярып кына.
Үлчим дисәм, уймак калды
Бармаккаемда...

Көч-хәлгә куптарып әни
Калайны алды,
Тик уймак эзе уелып
Бармакта калды.

КАЧЫШЛЫ УЙНЫЙБЫЗ

Кемнәрнең күзе очлы,
Әйдә, уйныйк качышлы.

Кем җитез, өлгер, зирәк,
Моны белү — бик кирәк.

Без саныйбыз меңгәчә,
Аннан мең дә бергәчә.

Саныйбыз такмак әйтеп,
Салмак, аннан тиз әйтеп.

Сез күзәтеп торыгыз,
Кемдә туктар кулыбыз?

Шул кеше сакта тора,
Ялкау булса, оттыра.

Уенбыз — качышлы,
Бер йөгереп алышлы.

УЗА ИДЕМ ИЛШАТНЫ

Әй, әйләнә карусель,
Йөгереп килде дә Марсель,
Атланды Тимеркүккә,
Очып китмәкче күккә.

Чаптыра атын егет,
Алдында дустын күреп.
«Җитәм, куып җитәм,— ди,—
Хәтта узып китәм,— ди,—

Әйдә, әйдә, малкаем,
Үзең тап шунда җаен.
Узыйк, узыйк Илшатны,
Алдагы җирән атны.»

Оча гына Тимеркүк
Даладагы җилләр күк.
«Уза идем,— ди,— Марсель,—
Туктамаса карусель...»

ЭШ ЭШЛӘМИ АРЫДЫМ

Мин йөгерәм, минем арттан
Күрәкләр куып килә,
Кычкыралар: «Ялкау малай,
Бездән качасың, нигә?»

Куаклар артына качкач,
Эзләп тапты тырмалар.
Сиптергечләр үч иткәндәй,
Каршымда ук торалар.

Өйгә керсәм, көтеп яткан
Себеркесе дә мине:
«Ялкау малай, һич булмаса,
Идәнне себер инде».

Балта тукылдый лапаста,
Пычкы зыңлый сарайда.
Тиешмен, имештер, утын
Турашырга бабайга.

Эш эшләми эштән чыктым,
Арыдым мин шулкадәр.
Арымас идем бу кадәр,
Эшләгән булсам әгәр...

КҮЗЕҢ КҮРГӘЧ

Үстем инде.
Үзем укыйм,
Тыңлап кына утырмыйм.
Әби әйтә: «Үзең белгәч,
Рәхәт ул — күзең күргәч.»

— Әй, әбием, әбием лә,
Күзем минем күптән күрә.
Беләсең килсә, бигрәк
Хәрефләрне тану кирәк.

ЧИГҮ ҖЕПЛӘРЕ БИРИК

Иртән торды да бер көнне
Хәйран калды Гөлчәчәк:
Тәрәзә пыяласында
Мең төрле гөл,
Мең чәчәк.

— Әни,— ди ул,— чәчәкләрне
Ак ситсага күчерик.
Я булмаса, кыш бабайга
Чигү җепләре бирик.

КОЯШЛЫ ТАБЫН

Иртәнге табын янында
Кашык, чокыр, тәлинкә.
Уртага чәчәк куелган,
Барсы нурга коенган.

Кояш уйный тәрәзәдә,
Бии өстәл өстендә,
Кояш минем битләремдә,
Коена чәем эчендә.

Сөлге, ашъяулык чугында,
Әниемнең йөзендә.
Кояш — туган ил күгендә,
Кояш — табын түрендә!

ЧИКЛӘВЕК —
ТӨШЕН ЭЧКӘ БИКЛӘВЕК

Дәү әнием бер тәвәч
Алып килгән күчтәнәч.

Күчтәнәче — чикләвек,
Төшен эчкә бикләвек.

Ашыгып капкан идем,
Зурысын ваткан идем,

Теш тикле теш кителде,
Ә иренем тишелде.

Тәүбә итмәде нәфсе,
Тагын кирәк, янәсе,

«Ал,— ди,— чүкеч кулыңа,
Аша кеше югында».

Ашыктым, ашка пештем,
Хыянәт итте чүкечем.

Тимгел, тимгел бармагым,
Кара көйде тырнагым.

И, син тәмле чикләвек —
Төшең эчкә бикләвек...

КҮНМИЛӘР КОШЧЫКЛАР

Әй, нәни кошчыклар,
Кечкенә чыпчыклар,
Ни салкын булып та,
Яшисез суыкта.

Дәү безнең өебез,
Әйдәгез, керегез.
Уйнарга яңадан
Бергәләп йөрербез.

Күнмиләр кошчыклар
Әйтәләр: «Кермим,— дип,—
Бер җылы почмакка
Иркемне бирмим»,— дип.

САНАП КАРА, НИЧӘ КОШ?

Бик матур кош, эшчән кош,
Бездә җәйли, китә кыш.
Кулы юк — балчык ташый,
Балтасы юк — өй ясый,
Диләр аның турында,
Бар ул Тукай җырында.

Тагын берсе җырчыбыз.
Моңлы сызгыручыбыз.
Песнәкләрнең бер төре,
Бик күпләргә билгеле,
Атаклы оста килеп,
Кубыз уйныйдыр кебек.

Ә соңгысы бик таныш:
Яратадыр көнбагыш.
Яңгырны да сизә ул,
Алдан хәбәр бирә ул.
Түсе аның кап-кара,
Буразна буйлап бара.

УЛ НӘРСӘ?

Әллә ничә иренле,
Теше дә әллә ничә.
Ярты басу арышын
Ашап бетергән кичә.

Комбайн.

ТОТ ЯХШЫ ТӘРБИЯДӘ

Яңгырларга бирешми,
Пычрак йөртү килешми,
Бернинди дым сеңдерми,
Тузганлыгын сиздерми.

Бөгәрләнми бөртек тә,
Ә һава яхшы үтә.
Йөз ел яшә, барыбер
Гомер буена җитә.

Лэкин онытма шуны,
Бик ярата ул суны,
Кояшны һәм сабынны,
Чыныкканда — салкынны.

Аннан башка беркем дә,
Яши алмый бер көн дә.
Тот яхшы тәрбиядә,
Нәрсә соң ул, әйт, әйдә!

Тән тиресе.

СЕЗДӘН ҖАВАП КӨТӘБЕЗ

Ләйлә чыкты урамга,
Сәйдә чыкты урамга.
Сәйдәнең көрәге бар,
Ләйләнең чиләге бар.

Ләйлә уйный комлыкта,
Сәйдә уйный комлыкта.
Тик бергә уйнамыйлар,
Тик бергә уйламыйлар.

Ләйлә уч белән комны
Тутыра чиләгенә,
Сәйдә көрәге белән
Тутыра күлмәгенә.

Ләйләнең кулы кара,
Ә Сәйдәнең — итәге.
Уйнадылар,
Уенның
Булмады һичбер тәме...

Бәлки, җавап бирерсез,
Уенның кая яме?

БОРЧАКЛАР

Борчаклар җиргә егылгач,
Кадап чыктым чыбыклар.
Аннан, күреп, исем китте,
Кара, нинди кызыклар!

Күрегез, күр, сез аларны,
Барсы торып утырган.
Куллары юк, ә үзләре
Чыбыкларга тотынган.

Мыеклары белән алар
Чорналганнар шулчаклы.
— Әй, шаян җил, хәзер менә
Егып кара борчакны!

КҮЗЛЕ КОЯШ

Кояшкаем, туры кара,
Серебезне бүлешик.
Күрмим ләкин күзләреңне,
Аңларга моны ничек?

Рәсемле китабымда
Бар иде бит күзләрең.
Ә урамда карап булмый,
Күреп булмый үзләрен.

ЧИШМӘ — БӘБИ, ЕЛГА — ӘНИ

Чишмә — бәби,
Елга — әни,
Челтер, челтер, челтери.
Бәби шулай дәү үсә дә,
Елга була, күп йөри.

Әйләнә күпме илләрне,
Тауларны, үзәннәрне.
Бик сөйлисе килсә әгәр
Юлында күргәннәрне,
Пар булып очып менә ул
Болытның канатына,
Җилдертеп толпар атында
Чаба чишмә катына.
Ә аннан соң,
Яңгыр булып,
Нәниенә эндәшә.
Чишмә — бәби,
Елга — әни
Әнә шулай сөйләшә...

БАР ШУНДЫЙ ҮЛӘН

Бар шундый бер «ут үлән»,
Ут түгел, бик мут үлән.
Оекларың тузганны,
Яланаяк узганны
Саклап кына тора ул,
Яндыра, кыздыра ул.

Еласалар бәбиләр,
Өзеп ала әбиләр.
Туктыйсыңмы, юкмы дип,
Ул бит менә утлы дип,
Тагын шуны тоталар,
Теңкәне корыталар.

Һәммәбез кыен күрә.
Түгел үзенә күрә,
Кычтый, кычтый, кычыткан.
Тамыры булыр кырыктан.
Үзен тотып пешерсәк,
Чага алмас кычыткан,
Кычтый, кычтый, кычыткан.

МӘКТӘП ЮЛЫ — ГОМЕР ЮЛЫ

Кулдан тотып әти-әни
Мәктәпләргә илтә туры.
Аллы-гөлле чәчкә белән
Башланадыр мәктәп юлы.

Алга илткән,
Янга киткән
Юллар белән дөнья тулы.
Кадер белсәң, кадерле итәр —
Чәчәкле юл — белем юлы.

БИЕМӘДЕ НУРСАДӘ

Без, без үсәбез,
Күлмәктә бар кесәбез.
Котлы булсын, диегез,
Тыпыр-тыпыр биербез.

Күлмәктәге кесәгә
Конфетлар күп керсә дә,
Яңа күлмәк котлатып,
Өйдән өйгә йөрсә дә,
Биемәде Нурсадә,
Шатланмады Нурсадә.
Нигә?

Чөнки аңа теш табибы
конфет капмаска кушкан...

ВАКЫТНЫ КЕМ ӘЙТКӘН?

Кызып барганда уен,
Таратып зиһен-уем,
Өзелеп карын ачты,
Уйнау теләге качты.

Сәгатькә карамаган,
Вакытны санамаган.
Беркем әйтми ләбаса,
Бу соң нинди тамаша?

Кем соң эш итә белеп,
Сигналлар биргән кебек?
Эндәшми бит әни дә:
«Улым, аш әзер»,— диеп.

Гадәт.

НИНДИ ИЛДӘ

Серле илдә, серле җирдә
Ике король яши, ди.
Бер-беренә алар мәңге
Берниндн сүз дәшми, ди.

Дошманнар ди, бер-берсенә
Алар борын-борыннан.
Серле солдатлар тезелгән,
Серле туплар корылган.

Серле ялларын тузгытып,
Серле атлар чаба, ди.
Тәхетне эле бер король,
Аннан
Икенчесе ала, ди.

Серле, ди, юллар, мәйданнар,
Корольләр үзләре дә.
Серле илдә — серле халык,
Табышмак менә сезгә.

Шахмат.

ТУКРАН

Каргалар туңганнар,
Тукран тирләгән.
— Ни өчен?
— Чөнки ул көн буе
Бөҗәкләр җирләгән...

МИНЕМ БАБАЙ

Минем бабам капитан,
Сугышта булып кайткан.
Күкрәк тулы орденнар,
Медальләр алып кайткан.

Безнең илдә һәр бала
Уйнап-көлеп йөрсен дип,
Хәвеф-хәтәр күрмәсен,
Тыныч булып үссен дип.

Көрәшкән чакта бабам,
Әни
Нәкъ минем яшьтә булган,
Рәсем ясап, хат язып,
Бабама салып торган.

Бик күп сугышкан бабам,
Дошманны җиңеп кайткан.
Үзе белән ул безгә
Тынычлык алып кайткан!

ҖИЛ КУБЫЗЫНА БИЮ

Сызгырсаң җил чыга, диләр,
Чыкса сызгырган саен,
Сынып төшәр иде күптән
Бакчабыздагы каен.

Төшеп карыйм бакча буйлап
Күлгә, үз турыбызга —
Ә анда таллар, камышлар
Бии җил кубызына.

Сызгырсаң җил чыга, диләр,
Чыкмас сызгырган саен,
Без пыр тузып йөгергәнгә
Чыгадыр ул, мөгаен.

ӘКИЯТЛӘР НИНДИ БУЛА?

Әкиятләр зәңгәр була,
Әкиятләр алсулар.
Әкиятләр сабыр була,
Әкиятләр ярсулар.

Әкиятләр җитез була,
Әкиятләр елгырлар.
Шундый әкият тыңла да,
Йокламыйча түз, ди бар...

ГАРМУНДА УЙНАГАНДА

Уйныйм, уйныйм,
Матур җырлар
Агыла да, агыла.
Көйләремдә
Чишмә моңы,
Кояш нуры чагыла.
Уйныйм, җырлыйм,
Әтием дә,
Әнием дә кушылсын.
Өебезгә,
Илебезгә,
Моңлы,
Нурлы җыр тулсын!

НӘНИ МУЗЫКАНТ

Сандугачлар сайрашамы,
Бал корты безелдиме,
Дәфтәремә язып куям
Откан бер яңа көйне.

Яфракларның бар үз җыры,
Тыңлап торам, таң калып.
Челтер-челтер чишмә ага,
«Си, ля, соль»,— дим шатланып.

Җилләр исә: «До-ре-ми-фа».
Яңгыр ява: «Соль-ля-си».
Менә тагын өр-яңа җыр,
Менә тагын яңа көй.

Көчек шыңшыган буламы,
Энем елыймы өйдә?
Тирә-юньдә күпме тавыш —
Барсын салам мин көйгә.

ЯҢГЫРКАЕМ, КАЕНКАЕМ

Яу, яу, яңгыркаем,
Тизрәк үссен каенкаем,
Минем чаклы булсын ул.
Яу, яу, яңгыркаем,
Тизрәк үссен каенкаем,
Буй-сыны булсын сылу.

Тукта, тукта, яңгыркаем,
Узып китте каенкаем
Былтыр ук инде мине.
Тукта, тукта, каенкаем,
Мин дә, мин дә, яңгыркаем,
Тизрәк үсәсе иде.

ЭЧТӘЛЕК

Гөл үстерә Гөлнара 3
Кояшлы уен 3
Серле дулкыннар 4
Елмаегыз, күләгез 5
Яз килә 5
Бүләк әзерләгәндә 7
Өмә көнне 8
Ничек түзгән? 8
Җәй ае 9
Ак юл кирәк 10
Яшел чыршы, яшь чыршы 11
Җәяүле буран 12
Авылга цирк килгәч 13
Ата каз 14
Үртәсен әле мине 16
Туйгачтын бал да әче 17
Резеда матур кыз 18
Курчакларның апасы 18
Рәсем дәфтәре 19
Кем булган әби-бабам? 20
Җиңел аяклы апа 21
Тәмлетамак Нәркис 22
Уеннан уймак 23
Качышлы уйныйбыз 24
Уза идем Илшатны 25
Эш эшләми арыдым 26
Күзең күргәч 28

Чигү җепләре бирик 28
Кояшлы табын 29
Чикләвек — төшен эчкә бикләвек . . 30
Күнмиләр кошчыклар 31
Санап кара, ничә кош? 32
Ул нәрсә? 33
Тот яхшы тәрбиядә 33
Сездән җавап көтәбез 34
Борчаклар 35
Күзле кояш 35
Чишмә — бәби, елга — әни 36
Бар шундый үлән 37
Мәктәп юлы — гомер юлы 38
Биемәде Нурсадә 38
Вакытны кем әйткән? 39
Нинди илдә? 40
Тукран 41
Минем бабам 41
Җил кубызына бию 42
Әкиятләр нинди була? 43
Гармунда уйнаганда 43
Нәни музыкант 44
Яңгыркаем, каенкаем 45

10 тиен